**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2021 елның 13 апреле 106№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 13 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 160 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2019 елның 27 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү турында"гы 449-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 6 февралендәге «Эчке дәүләт (муниципаль) финанс контролен гамәлгә ашырганда эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары вазыйфаи затлары һәм бурычлары һәм эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроле объектларының (аларның вазыйфаи затлары) хокуклары һәм бурычлары» эчке дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүенең федераль стандартын раслау турында»гы 100 номерлы Карары нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Карар бирә:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 13 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 160 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктның м пунктчасында "дәүләт адресына" сүзләреннән соң (муниципаль) сүзен өстәргә;

11 пунктының д пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"д) тикшерү объекты җитәкчесен (вәкилен) тикшерү объекты җибәрелергә тиешле контроль органы документларының күчермәләре белән тикшерү чарасын уздырганда, тикшерү чарасын туктатканда, яңарту һәм үткәрү вакытын

озайтканда ,рәсмиләштерелә торган документларның күчермәләре, тикшерү (ревизия) төркеменең составын үзгәрткәндә, шулай ук контроль чаралар нәтиҗәләре (актлар, бәяләмәләр) белән таныштырырга;";

10 пунктның 6 абзацы г пунктчасында "башка дәүләт" сүзләреннән соң "(муниципаль)" сүзләрен, " Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органы "сүзләреннән соң" (муниципаль хезмәткәр)", "(җирле үзидарә органы)"сүзләрен өстәргә";

10 пунктның 3 абзацы г пунктчасында "башка дәүләт" сүзләреннән соң "(муниципаль)" сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" бастырып чыгарырга һәм Әлки муниципаль районының рәсми alkeevski.tatarstan.ru сайтында халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге начальнигына йөкләргә.

Җитәкче: И. В. Юсупов